ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларның һәм хосусый гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның туклануын оештыру чараларын өстәмә финанс белән тәэмин итәргә, балаларга өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә, шул исәптән балаларга өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәм хосусый белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итәргә, муниципаль мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган урта гомуми белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программасы чикләрендә эшче һөнәрләренә, хезмәткәрләр вазыйфаларына һөнәри әзерлек программалары буенча һөнәргә өйрәтүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә, Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган, дәүләт аккредитациясе булган урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программасы, урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары чикләрендә эшче һөнәрләренә, хезмәткәрләр вазыйфаларына һөнәри әзерлек программалары буенча һөнәргә өйрәтүне оештырырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 март
№ 8-ТРЗ